ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 532 от «18»05 2016 г.

2016 елда Мамадыш муниципаль
районы территориясендә бердәм
дәүләт имтиханы һәм бердәм
республика имтиханы үткәрү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законның 59 статьясындагы 13 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 19.01.2016 ел, 39 – б санлы боерыгы нигезендә, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштергән белем алучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты МКУ “Мәгариф бүлегенә” (Габдрахманов И.Н.):

- 2018 елда бердәм дәүләт имтиханын үткәрүне тәэмин итәргә;
- 2018 елда урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» фәннәрен өйрәнгән һәм алар буенча имтихан сайлап алган укучылар дәүләт йомгаклау аттестациясен үтү өчен «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» фәннәре буенча бердәм дәүләт һәм бердәм дәүләт республика имтиханын үткәрергә;
- үз компетенциясе чикләрендә бердәм дәүләт һәм бердәм республика йомгаклау аттестациясе үткәрүнең мәгълүмати һәм норматив – хокукый яктан тәэмин итәргә;
- бердәм дәүләт һәм бердәм республика йомгаклау аттестациясен инструктив-методик, оештыру һәм мәгълүмати яктан тәэмин итәргә.

2. Дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрү пункты итеп МБГБУ “Мамадыш шәһәре өченче номерлы урта гомуми белем мәктәбен” билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Сергеев А.М.) дәүләт йомгаклау аттестациясен, шул исәптән республика имтиханын үткәрү чыгымнарын финанслар белән тәэмин өчен каралган акчаларның Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының МКУ “Мәгариф бүлегенең” нормативлар билгеләнгән сметасына нигезләнеп, үз вакытында кучүен тәэмин итәргә.

4. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлегенә бердәм дәүләт һәм бердәм республика йомгаклау аттестациясен, шул

исәптән республика имтиханын үткәрү пунктлары янындагы территорияләрдә җәмәгать тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә белем бирү оешмалары администрацияләренә булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Мамадыш үзәк район хастаханәсенә (Хазиев Д.Ф.) бердәм дәүләт һәм бердәм республика йомгаклау аттестациясен үткәрү пунктларында медицина персоналы кизүен оештыруда булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П.Смирновага йөкләргә.

Җитәкче С.М. Гыймранов